| | |
|---|---|
| **Исполнительный комитет Старочукалинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Башкарма комитеты** |

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1061672003876 ИНН 1617003290 КПП 161701001

==========================================================

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 1 февраль 2019ел № 4

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Иске Чокалы
авыл җирлегендә кече һәм урта
эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны
үстерү буенча Координация советы төзү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү буенча Координация советы төзергә.( Кушымта №1)
2. Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү буенча Координация советы турындагы нигезләмәне расларга. (Кушымта №2)
3. Әлеге карарны Иске Чокалы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Низамутдинов

Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитетының 01.02.2019 елның №4 карарына 1 енче кушымта.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү буенча Координация советының составы

1.Низамутдинов Рамис Рафагат улы- Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы, Координация советының рәисе.

2.Якупова Илсөяр Фиалит кызы - Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитетының сәркәтибе.

3. Низамов Дамир Абдрахман улы- шәхси эшмәкәр, Координация советы рәисе урынбасары.

4. Хайрутдинов Ильгам Иршат улы – Иске Чокалы авыл җирлеге депутаты (килешү буенча), комиссия әгъзасы.

5.Сабирзянов Ильдус Җәффәр улы– Иске Чокалы авыл җирлеге депутаты (килешү буенча), комиссия әгъзасы.

Иске Чокалы авыл җирлеге
башкарма комитетының 01.02.2019
елның №4 карарына 2 нче кушымта

Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү буенча Координация советы турындагы нигезләмә

**I.Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында " 2007 елның 24 июлендәге 209 – ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп эшләнгән.

Татарстан Республикасы Чүпрәле районы Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитетында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү буенча Координация советы (алга таба Координация советы) базар икътисады шартларында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә стратегик юнәлешләрне билгеләү максатларында авыл җирлеге башкарма хакимияте органнарының, иҗтимагый оешмаларның һәм эшкуарлык даирәләре вәкилләренең гамәлләрен консультацияләүне тәэмин итә торган даими эшләүче консультатив – киңәшмә органы булып тора.

Координация советы юридик зат түгел һәм үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

Координация советы үз эшчәнлеген Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

Координация советы үз эшчәнлегендә дәүләт хакимияте органнары, районның җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар һәм эшмәкәрлек структуралары белән хезмәттәшлек итә.

**II. Төп бурычлар**

Координация советының төп бурычлары:

- Дәүләт икътисадый сәясәтен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

- районда кече һәм урта эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме һәм аны үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен, принципларын, стратегияләрен эшләү;

- кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын эшләүдә һәм тормышка ашыруда булышлык күрсәтү;

- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүнең максат һәм бурычларын, уңай тәҗрибәсен пропагандалау.

**III. Функцияләре**

Төп бурычлар нигезендә Координация советы түбәндәге функцияләрне башкара:

- районда кече һәм урта эшмәкәрлек торышы мониторингы нәтиҗәләрен карый;

- кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү стратегиясе һәм тактикасы буенча авыл җирлеге башлыгына тәкъдимнәр кертә;

- инвестицияләрне, алдынгы технологияләрне һәм идарә тәҗрибәсен җәлеп итү һәм куллану буенча тәкъдимнәр әзерли;

- кече һәм урта эшкуарлык мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагыла торган Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары проектларына экспертиза оештыра, эшкуарлык эшчәнлегенең төрле мәсьәләләрен җайга салучы гамәлдәге законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

- проектларны карый һәм кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программаларының үтәлеше барышын анализлый;

- кече һәм урта эшмәкәрлекнең әһәмиятен күтәрүгә юнәлдерелгән мәгълүмати мохит булдыруга ярдәм итә, эшмәкәрлек инициативасының үсешенә, эшкуарларны икътисадый рәвешләрне эшләү һәм гамәлгә ашыру процессына җәлеп итүгә ярдәм итә.

**IV. Хокуклары**

Төп бурычларны гамәлгә ашыру өчен Координация советы хокуклы:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә юнәлдерелгән карарлар проектларын әзерләүдә катнашырга;

- башкарма хакимият органнарыннан, хуҗалык итүче субъектлардан Координация советы эше өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

- кирәк булганда, билгеләнгән тәртиптә консультантлар сыйфатында тиешле белгечләрне җәлеп итәргә;

- билгеләнгән тәртиптә конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен эшче төркемнәр төзү һәм әлеге төркемнәрнең эш тәртибен билгеләү;

- районда кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүнең актуаль проблемалары буенча аналитик язмалар әзерләргә.

**V. Эшчәнлекне оештыру**

Координация советын Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы җитәкли. Координация советы составына паритет нигездә авыл җирлеге башкарма хакимияте органнары вәкилләре һәм тиешле җәмәгать берләшмәләре органнары тарафыннан билгеләнә торган кече һәм урта эшмәкәрлек вәкилләре керә. Координация советы утырышлары рәис тарафыннан расланган эш планы нигезендә, кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, Координация советы утырышы хаклы санала. Утырышка көн тәртибе, шулай ук аны үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат, Координация советы әгъзаларына утырышка кадәр өч көн алдан җибәрелә. Координация советы карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышларның тигез саны булганда, Координация советы рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Координация советын Бетерү Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән башкарыла.